ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.09.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2450**

Татарстан Респуубликасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы, 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 октябрендәге 329 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 433 номерлы, 2021елның 24 мартындагы карарларында кертелгән үзгәрешләре белән) нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Респуубликасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне , әлеге Карарга кушымтада каралганча, расларга.
2. Түбәндәге карарлар үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 18 июлендәге 1872 номерлы карары;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 28 августындагы 1713 номерлы карары.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
16.09.2022 № 2450

**Татарстан Республикасы**
**«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары составында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан (алга таба - Резерв фонды) Зеленодольск муниципаль районының көтелмәгән чыгымнарын финанслауга акчалата чараларны формалаштыру һәм тоту тәртибе билгеләнә.

1.2. Резерв фондының акчалата чаралары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле тиешле финанс елына бюджетның чыгым өлешендә каралмаган көтелмәгән чыгымнарны финанслау өчен билгеләнгән һәм киләсе финанс елына бюджет расланганчы кичектерелә алмый.

2. Резерв фондын формалаштыру тәртибе

2.1. Резерв фонды Зеленодольск муниципаль районы бюджеты чыгымнары составында төзелә.

2.2. Резерв фонды күләме Зеленодольск муниципаль районы бюджетын раслаганда Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә һәм Зеленодольск муниципаль районы бюджеты чыгымнарының расланган гомуми күләменең өч процентыннан арта алмый.

2.3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы карарлары көтелмәгән чыгымнар барлыкка килгән очракта кабул ителә.

3. Резерв фондыннан акчаларны тоту юнәлеше

Резерв фондының акчалата чаралары түбәндәгеләрне финанслауга тотыла:

– көтелмәгән чыгымнарга, шул исәптән агымдагы финанс елында булган табигый бәла - казалар һәм җирле дәрәҗәдәге башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча авария-торгызу эшләрен башкаруга;
– кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләре уздыруга;
– иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә ярдәм итү өчен;
– район (шәһәр) һәм республика әһәмиятендәге чаралар уздыруга;
– бүләкләр һәм юбилей медальләр әзерләүгә;
– район (шәһәр) һәм республика әһәмиятендәге очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар уздыруга;
– Зеленодольск муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен гражданнарга, учреждение, оешма һәм предприятие хезмәткәрләренә премияләр түләүгә, матди булышу һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә;
– гражданнарга табигый бәла-казалардан һәм янгыннан зыян алганда бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүгә;
– гуманитар ярдәм күрсәтүгә;

– социаль-мәдәни һәм яшьләр өлкәсен, физик культураны һәм спортны үстерүгә ярдәм итүгә;

– үзләре белән бәйле булмаган хәлләр буенча авыр матди хәлдә калган һәм ашыгыч медицина ярдәменә мохтаҗ гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүгә;

– Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары буенча үткәрелә торган башка чараларга.

Резерв фонды акчалары гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанслауга бүлеп бирелә һәм табигый бәла-казалардан һәм җирле әһәмияттәге янгыннан зыян килгән очракта бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләүләрен бүлеп бирүгә тотыла .

## Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү тәртибе

4.1. Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренең, учреждениеләрнең, оешмаларның, предприятиеләрнең һәм физик затларның мөрәҗәгатьләре нигезендә, әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән акчалар бүлеп бирү өчен нигезләрне раслый торган документлар кушымтасы белән, смета-финанс исәп - хисапларын, кирәк булган очракта-экспертлар, комиссияләр бәяләмәләрен дә кертеп, карала .

4.2. Алучы турында белешмәләрдән, бүлеп бирелә торган акча күләменнән һәм аларны максатчан тотудан яки акча бүлеп бирүнең максатка ярашлы булмавы турында бәяләмәдән гыйбарәт булган, «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе тапшырылган документлар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә күрсәтмә проектын әзерли һәм җибәрә.

4.3. Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы карар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карамагында каралмаган максатларга акчаларны куллану рөхсәт ителми.

4.4. Табигый бәла-казалардан һәм янгыннан зыян килгән очракта, бер тапкыр бирелә торган матди ярдәмне түләү, табигый бәла-казалар һәм янгын нәтиҗәсендә зыян күргән, башка торак урыны милектә, файдаланууда булмаган гражданнарга(милекчеләргә, торак урыннарын яллаучыларга) бирелә.

4.5. Табигый бәла-казалардан һәм янгынга зыян китергәндә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күләме әлеге Нигезләмәнең 4.1 п. күрсәтелгән документлар нигезендә билгеләнә, әмма хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән биш минималь күләменнән арта алмый.

4.6.Зеленодольск муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен гражданнарга, учреждение, оешма һәм предприятие хезмәткәрләренә премияләр түләүгә, матди булышу һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, Зеленодольск муниципаль районында яшәүче гражданнарга хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән биш минималь күләменнән артыграк булганда, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының өстәмә карарлары нигезендә түләнә.

## 5. Резерв фондының акчаларын тоту һәм аннан файдалануны тикшереп тору турында хисап

5.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Резерв фондыннан акчалар бүленә торган учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр хисап елыннан соң килүче елның 20 числосына кадәр

«Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалану турында мәгълүмат бирәләр.

5.2. Резерв фонды акчаларыннан максатчан файдаланмау Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бәхәссез тәртиптә тартып алынырга тиеш.

5.3. Резерв фонды акчалары исәбеннән бүлеп бирелгән чыгымнар Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре һәм статьялары буенча үтәлеше хисаплылыгында чагыла.

5.4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Резерв фонды бюджет ассигнованиеләрен куллану турындагы хисап Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка кушымта итеп бирелә.

5.5. Резерв фондыннан бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын Зеленодольск муниципаль районы Советы, «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе, «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе контрольдә тота.